МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.02.2023 Казан шәһәре № 22-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Посейдон» коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 25 апрелендәге 232 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2016 елның 23 мартындагы 54-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2018 елның 29 гыйнварындагы 18-ОД номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның «б» пунктчасында «Президентының» сүзен «Рәисенең» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктта «Президентының» сүзен «Рәисенең» сүзенә алмаштырырга;

16.5 пунктта «кызыксынган оешмалар» сүзләреннән соң «, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасы кулланылырга мөмкин, шул исәптән гаризалар юллау өчен дә» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко